КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 11 ноябрь г.Казань № 985

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары белән расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1475 нче; 2023 ел, 18 апрель, 487 нче; 2023 ел, 19 декабрь, 1638 нче; 2024 ел, 16 апрель, 257 нче; 2024 ел, 16 сентябрь, 791 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар

буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, 3.2 пунктның унҗиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«заявка кысаларында идарә итүче компания тарафыннан капларга планлаштырыла торган кредит шартнамәсе буенча процентлар исәпләнгән чор өчен төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешмадан эш төрләре яктылыгында башкарылган һәм кабул ителгән төзелеш-монтаж эшләре турында мәгълүмат белән белешмә кәгазе; аңа КС-2 формасы буенча индустриаль парк инфраструктурасын булдыруга башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре, индустриаль парк инфраструктурасы объектлары төзелешенең барышын раслый торган фотоматериаллар һәм үз-үзен җайга сала торган оешма әгъзаларының реестрыннан әлеге абзацта күрсәтелгән оешманың төзелеш контролен гамәлгә ашыру хокукын раслый торган өземтә күчермәләре теркәлә. Әгәр объект файдалануга тапшырылган булса, КС-2 формасы буенча индустриаль парк инфраструктурасын булдыруга башкарылган эшләрне кабул итү турында актлар күчермәләре, индустриаль парк инфраструктурасы объектлары төзелешенең барышын раслый торган фотоматериаллар тапшырылмый, КС-14 формасы буенча төзелеше тәгәлләнгән объектны кабул итү акты һәм файдалануга тапшырылган объект фотоматериаллары тапшырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин